Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

___24.03.2022______ Менделеевск ш. № _____201______

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче
гражданга туры килә торган керемнең
һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче
граждан милкендәге һәм 2022 елга салым
салынырга тиешле мөлкәт хакының
чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, нигезендә Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган предприятиесенең 2022 елның 14 ноябрендәге эксперт-консультация советы Хаты, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьясы һәм Россия Федерациясе Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгына нигезләнеп һәм Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 671148 сум;

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1342296 сум;

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2013444 сум;

«1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2684592 сум;

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 3355740 сум;

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 402688 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 4698036 сум;

1.1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 5369184 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме, хисап (1 нче кушымта) нигезендә:

1.2.1. Бер кеше өчен - 14940,11 сум;

2. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә, шәһәр хуҗалыгына һәм сәүдә бүлегенә, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда. әлеге карарның 1.1. һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга,

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.И.Беляев

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 мартындагы
201   номерлы карарына
кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2022 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү МЕТОДИКАСЫ**

**1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:**

**СЖ = НП х РС х РЦ**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урынны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

а) бер кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286 х 18 х 1 = 671148 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286 х 18 х 2 = 1342296 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286  х 18 х 3 = 2013444 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286  х 18 х 4 = 2684592 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286  х 18 х 5 = 3355740 сум

е) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286 х 18 х 6 = 4026888 сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286 х 18 х 7 = 4698036 сум

3) сигез кешелек гаиләгә:

СЖ = 37 286 х 18 х 8 = 5369184 сум

**2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең чик күрсәткече:**

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС)** $^{-КП}$ **) / (0,3 х РС)**

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик әһәмияте;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) 0,0083%, (10,01/12/100).

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2014 елның 14 гыйнварындагы 44 номерлы «ТР бәяләүчеләр берлеге» НП эксперт-консультация советының хаты нигезендә Менделеевск шәһәрендә һәм Менделеевск муниципаль районында торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 37 286 сум тәшкил итә.

**һәр гаилә әгъзасына туры килә торган керемнең чик әһәмияте исәп-хисабы**

а) бер кешелек гаиләгә

ПД=0,7х671148,00х0,0083/ (1 - (1 + 0,0083) $^{-240}$ ) / (0,3 х 1)= **14940,11 рублей**

б) ике кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 2 = **29880,22 сум**

в) өч кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 3 = **44820,33 сум**

г) дүрт кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 4 = **59760,44** сум

д) биш кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 5 = **74700,55** сум

е) алты кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 6 = **89640,66** сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 7 = **104580,77** сум

з) сигез кешелек гаиләгә:

ПД = 14940,11 х 8 = **119520,88** сум